**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«15» сентябрь, 2021 ел** **№ 104**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарында гражданнарның муниципаль хезмәткә урнашуга тигез мөмкинлеге өлешендә муниципаль хезмәтнең төп принципларын гамәлгә ашыру максатларында, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставына таянып, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2017 елның 30 мартындагы 127 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәгә (Советның 07.08.2017 № 160, 22.05.2020 № 373 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 14 пунктның б) пунктчасында «автобиографияне» сүзен төшереп калдырырга;

2) Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә кушымтаның 2) пунктында «автобиографияне» сүзен төшереп калдырырга;

3) 24 пунктны түбәндәге эчтәлекле икенче абзац белән тулыландырырга:

«Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарны бәяләү өчен Россия Федерациясе Конституциясен һәм Татарстан Республикасы Конституциясен, муниципаль хезмәт турындагы, коррупциягә каршы көрәш турындагы законнар нигезләрен белүне үз эченә алган, Татарстан Республикасы кадрларын бәяләүнең махсус эшләнгән системасында уздырыла торган тестлаштыру (60 сорау) рәвешендә сораулар кертергә»;

4) 25 пунктта «нәтиҗәләре буенча» сүзләре алдыннан « һәм тестлаштыру » сүзләре белән тулыландырырга:

5) 28 пунктта «нәтиҗәләре буенча» сүзләре алдыннан « һәм тестлаштыру » сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-

gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә һәм җәмәгатьчелек белән элемтә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Г. Кәлимуллин